СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2019 г. Заинск № 457

**Зәй муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә, Зәй муниципаль район Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга (Кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Район Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль район
Советы карарына кушымта
17.12.2019 № 457

**Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Зәй муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләре**

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр) тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлек бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет).

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында»2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәплләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү Зәй муниципаль районы Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Граждан хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылу өлешендә субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

хезмәткә түләү һәм хезмәт өчен түләү хисаплау;

командировка чыгымнары;

элемтә хезмәтләре;

транспорт хезмәтләре;
коммуналь хезмәтләр;
мөлкәтне файдалану буенча хезмәтләр;
мөлкәтне карап тоту буенча эшләр, хезмәтләр;
башка эшләр, хезмәтләр;
төп чаралар сатып алу;
матди запаслар сатып алу;
салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү;
башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – казначылык) җирлек бюджетлары үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турындагы хисапны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләрнең Башкарма комитетына тапшыралар.

12. Башкарма комитетка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына билгеләнмәгән субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты һәм финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.